**«Мәгарифтә лидерлык: стратегик ориентирлар һәм технологияләр»**
**2024 елгы мәгариф һәм фән хезмәткәрләре республика август киңәшмәсе**
**РЕЗОЛЮЦИЯСЕ**

2024 елның 15 августы

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2024 елның 15 августында мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең «Мәгарифтә лидерлык: стратегик ориентирлар һәм технологияләр» республика август киңәшмәсе уздырылды.

Киңәшмә барышында мәктәпкәчә һәм урта белемнең сыйфатын яхшырту һәм һәркем, шул исәптән сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен дә, файдалана алырлык булу; «Россия Мәгариф министрлыгы мәктәбе» проектын гамәлгә ашыру контекстында бердәм белем бирү киңлеген булдыру һәм укучыларның конституциячел хокукларын тәэмин итү, балаларга өстәмә белем бирү һәм аның инфраструктурасын үстерү; мәктәпнең тәрбияви потенциалын үстерү, идеологик тәрбия эше үзенчәлекләрен исәпкә алып, ата-аналарның педагогик белемен арттыру бурычлары; дәүләт телләрен һәм туган телләрне саклау һәм үстерү өчен белем бирү киңлеген булдыру; ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар мәнфәгатьләрендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру; белем бирү процессын цифрлаштыру; һөнәри белем бирүне камилләштерү, педагогик кадрлар әзерләү һәм аларның үсешен тәэмин итүнең яңа механизмнарын гамәлгә кертү; «Мәгариф», «Пилотсыз авицион системалар» милли проектларын, Татарстанда фәнни-технологик үсеш елына багышланган чараларны гамәлгә ашыруга бәйле актуаль мәсьәләләр каралды.

2024/25 уку елына региональ белем бирү сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре 2024 елның 7 маенда 309 номеры белән кабул ителгән «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының стратегик мөһим норматив документлары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2023 елның 14 сентябрендәге Юлламасы нигезендә билгеләнде.

Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүнең барлык юнәлешләренең концептуаль ориентиры – «Мәгариф» илкүләм проектының төп максатына ирешү – Россия мәгарифенең глобаль конкурентлык сәләтен тәэмин итү, Россия Федерациясенең гомуми белем бирү сыйфаты буенча дөньяның әйдәп баручы илләре исәбенә керүе һәм республика халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләре, аларның тарихи һәм милли-мәдәни традицияләре нигезендә гармонияле үсеш алган, сәламәт һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

Региональ мәгариф системасы торышын чагылдырган һәм аның үсеш юнәлешләрен билгеләгән сыйфат һәм сан күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора.

**Мәктәпкәчә белем бирү системасында:**

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары челтәре

(барлыгы 1 945 оешма) эшли, шуларның 1 654 е – балалар бакчасы, 291 е – мәктәпкәчә төркемнәре булган мәктәп, шул исәптән 38 е – шәхси балалар бакчасы. Аларда мәктәпкәчә яшьтәге 200 мең бала тәрбияләнә, бу 1 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларның гомуми саныннан 73,1 % тәшкил итә.

Республиканың һәр муниципаль районында барлык яшь категориясендәге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеге 100 процентны тәшкил итә. Республикада ел саен өстәмә мәктәпкәчә урыннар булдыру чаралары гамәлгә ашырыла.

Агымдагы елда гомуми сыйдырышлылыгы 2 220 урын булган 10 балалар бакчасы төзелә. Шул исәптән торак төзелеше интенсив барган Лаеш, Питрәч, Биектау муниципаль районнарында ике балалар бакчасы сафка басачак.

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль программасы кысаларында шулай ук балалар өчен өстәмә урыннар булдырыла. Апас муниципаль районында 80 урынлык балалар бакчасы төзелеше бара.

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемне туган телдә алу хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырыла. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының 729 ы – татар телендә, 51 е – чуваш телендә, 15 е – удмурт телендә, 8 е – мари телендә, 1 се – мордва телендә тәрбия һәм белем бирә. Балаларны туган (рус булмаган) телдә укыту һәм тәрбияләү күрсәткече 56,8% тәшкил итә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында гаиләгә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү һәм ата-аналарның мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү мәсьәләләрендә компетентлыгын арттыру максатларында мәктәпкәчә белем бирү оешмалары базасында консультация пунктлары (үзәкләре) эше оештырыла. Аларның эшчәнлеге мәгариф белән идарә итү муниципаль органнарының норматив-хокукый актлары һәм (яисә) мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының локаль актларына нигезләнеп оештырыла. 2019 елдан 2024 елга кадәр 41 балалар бакчасы базасында консультация пунктлары булдырылды. 2024 елда 4 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча җиңүче дип танылды, «Балалар бакчасы – үсеш маршрутлары» федераль грантына лаек булды.

Республикада компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәре булган 599 балалар бакчасы эшли, аларда 18 меңнән артык мәктәпкәчә яшьтәге бала тәрбияләнә. Мондый төркемнәрнең төп өлеше – логопедик юнәлештә (сөйләмендә тайпылышлар булган балалар өчен). 106 балалар бакчасында күрү, ишетү, интеллект, терәк-хәрәкәт аппараты тайпылышлары булган балалар өчен төркемнәр төзелде.

Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда эшләүче педагоглар саны

агымдагы ел башында 20 677 кеше, шул исәптән 14 960 тәрбияче, тәшкил итте.

2023/24 уку елында мәктәпкәчә белем оешмаларының 7 930 педагогы квалификация күтәрү курслары узды. Агымдагы елда педагоглар һәм балалар бакчалары җитәкчеләре тарафыннан квалификация күтәрү курсларында уку өчен 5 743 гариза тапшырылган.

«Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы – 2023» бөтенроссия һөнәри бәйгесендә беренче тапкыр «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телдә сөйләмен үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләре» номинациясе кертелде. Казан шәһәре Вахитов районы 41 нче мәктәпнең мәктәпкәчә белем бирү төркеме тәрбиячесе Лотфуллина Айсылу Газинур кызы абсолют җиңүче исеменә лаек булды. Россиянең иң яхшы тәрбиячеләре бишлегенә Казан шәһәренең Киров районы 101 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Токмакова Юлия Анатольевна керде.

Мәктәпкәчә белемне үстерүдә кече яшьтәге балалар өчен полилингваль белем бирү актуаль юнәлеш булып тора. Ул берничә телдә белем һәм тәрбия бирүне оештыру, балаларны өйрәнелә торган тел чаралары аша Россиянең күпмилләтле халкының мәдәни байлыгына якынайту һәм аларны милләтара татулык рухында тәрбияләүне күздә тота.

Ел саен үткәрелә торган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантына республиканың 20 иң яхшы балалар бакчасы лаек булды.

Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем оешмалары Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт үткәрә торган мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын бәяләүдә (алга таба – мониторинг) катнашалар. 2024 елда мониторингта республиканың 144 балалар бакчасы туганнан башлап 7 яшькә кадәрге балалар өчен камилләштерелгән инструментарийны кулланып катнашты. 2024 елда мониторинг үткәрелмәячәк.

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмендә, республикабызда традицион әхлакый кыйммәтләрне исәпкә алып, балаларда һәм яшүсмерләрдә актив патриотик позиция булдыру максатыннан шефлык эшен торгызу һәм Татарстан Республикасында белем алучы балалар һәм балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне оештыру аша «Беренчеләр Хәрәкәтендә мәктәпкәчә мәгариф оешмалары» пилот проекты гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 60 пилот балалар бакчасы билгеләнгән. Бүгенге көндә проектта 1 763 бала катнаша. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының предмет-пространство мохитен рәсмиләштерү элементлары һәм методик, мәгълүмати материаллар эшләнде.

Гомумән алганда, соңгы елларда республикада мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә мәгариф сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән бурычлар уңышлы хәл ителә:

балалар бакчаларында өстәмә мәктәпкәчә урыннар булдыру чаралары гамәлгә ашырыла;

квалификация күтәрү системасы камилләштерелә;

балаларга республиканың дәүләт телләренә, туган телләргә өйрәтү өчен методик база төзелде;

эшчәнлекләре балаларга белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләрендә ата-аналарның компетентлыгын арттыруга юнәлтелгән мәктәпкәчә мәгариф оешмалары базасында консультация үзәкләре челтәре киңәя.

Шул ук вакытта чишелеш таләп итә торган методикага, кадрларга, идарә итүгә бәйле түбәндәге бурычлар да бар:

мәктәпкәчә белем бирүнең федераль белем бирү программасы нигезендә төзелгән программаларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

белем бирү процессын туган телдә оештыру юнәлешендә педагогларның компетентлыгын арттырырга;

сәламәтлекләре чикләнгән балаларга мәктәпкәчә белем бирү өчен шартлар тудырырга;

Гаилә елына багышланган чараларны оештыру эшен дәвам итәргә;

мәктәпкәчә яшьтәге балаларга иртә һөнәри юнәлеш бирү эшен камилләштерергә.

**Гомуми белем бирү системасында (башлангыч, төп, урта гомуми белем):**

Региональ мәгариф системасында 1 402 мәктәп (1 313 гомуми белем бирү мәктәбе һәм мәктәп-интернат, 53 сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп һәм мәктәп-интернат, 2 санатор мәктәп-интернат, 1 девиант тәртипле балалар өчен мәктәп, 7 кичке гомуми белем бирү мәктәбе, 24 дәүләтнеке булмаган мәктәп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы 2 гомуми белем бирү мәктәбе). Барлыгы 501 459 кеше белем ала.

Гомуми белем бирү өлкәсендә белем бирүнең сыйфатын күтәрү һәм аның яшәү урынына бәйсез рәвештә һәркем файдалана алырлык булуы мәсьәләләре уңышлы хәл ителә:

«Россия Мәгариф министрлыгы мәктәбе» проекты гамәлгә ашырыла;

белем бирү киңлегенең бердәмлеге һәм укучыларның конституциячел хокукларын тәэмин итү кысаларында яңартылган федераль дәүләт башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә республика мәктәпләренең 1-3 һәм 5-7 сыйныфларында һәм пилот режимында – «1-8 класслар», 10-11 сыйныфларда урта гомуми белем моделе буенча белем бирү программалары гамәлгә ашырыла;

республикада полилингваль белем бирү системасын булдыру һәм үстерү проектын гамәлгә ашыру дәвам итә, Казан, Яр Чаллы, Алабуга, Түбән

Кама һәм Әлмәт шәһәрләрендә, Актаныш муниципаль районында 6 полилингваль комплекс төзелде һәм эшли;

сыйфатлы гомуми белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча максатчан эш алып барыла, сәләтле укучыларны, шулай ук сәламәтлекләре чикләнгән балаларны укытуның индивидуаль белем бирү траекторияләре эшләнә, укытуның һәм тәрбияләүнең яңа ысуллары кертелә, белем бирү процессына аларның мотивациясен арттыруны тәэмин итә торган заманча белем бирү технологияләре гамәлгә куела; профильле укыту моделе формалаштырылган, аның кысаларында заманча җиһазлар белән җиһазландырылган авиа-, суднолар төзү сыйныфлары, энергосыйныфлар, «Промхимтех» сыйныфлары, медицина сыйныфлары, агросыйныфлар, экология сыйныфлары, геологик сыйныфлар, IT-сыйныфлар һәм башкалар аша уңышлы практика һәм нәтиҗәләр демонстрацияләнә;

лидерлык позицияләрендә булган мәгариф оешмалары базасында белем бирүнең ресурс үзәкләрен булдыру, шул исәптән белем бирүнең сыйфатын тәэмин итү, заманча технологик мохит тудыру, укучыларны тәрбияләү һәм социальләштерү системасы, аларның һөнәри үзбилгеләнеше буенча проектлар гамәлгә ашырыла (15 кадет мәктәбе һәм мәктәп-интернаты; сәләтле балалар өчен 15 махсуслаштырылган мәктәп; «Инженерлык республикасы» проектының 10 профильле мәктәбе, 33 «РОСНАНО» мәктәбе);

олимпиада хәрәкәте актив үсә; республика Россия һәм халыкара дәрәҗәдә үзенең алдынгы позицияләрен саклый (24 фән буенча Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча 3 нче урын һәм катнашуның нәтиҗәлелеге буенча 2 нче урын);

белем бирүнең сыйфатын бәяләүнең региональ моделе камилләштерелә, аның кысаларында белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы уздырыла; белем бирү нәтиҗәләре түбән булган һәм белем бирү нәтиҗәләренең кимү куркынычы булган мәктәпләргә адреслы ярдәм күрсәтелә; республиканың муниципаль районнарында укыту-методик эшчәнлекне камилләштерү буенча Координация советы үзенең эшен дәвам итә, аның максаты – сыйфат күрсәткечләре түбән булган районнарга һәм мәктәпләргә методик ярдәм күрсәтү; күрсәткечләре югары һәм күрсәткечләре түбән булган мәктәпләрнең нәтиҗәләрендәге аерма кимү;

Татарстан Республикасының социаль сәясәтендә инклюзия концепциясен гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлек итүнең ведомствоара планын гамәлгә ашыру дәвам итә.

**Мәгарифне цифрлы трансформацияләү өлкәсендә:**

заманча һәм куркынычсыз цифрлы белем бирү мохитен булдыру максатларында белем бирү оешмалары «Мәгариф» милли проекты

кысаларында заманча мәгълүмат-коммуникация җайланмасы белән тәэмин ителде;

белем бирү оешмаларында мәгълүматлар тапшыруның бердәм челтәре кысаларында дәүләт, муниципаль һәм башка мәгълүмат системаларына, шулай ук Интернет челтәренә куркынычсыз керү оештырылды;

белем бирү оешмаларында «Цифр дәресе», «Интернет челтәрендә бердәм иминлек дәресе», «Цифрлы ликбез» мәгариф акцияләре дәвам итә, «Киләчәк коды» федераль проекты, «Яндекс.Лицей» мәгариф проекты гамәлгә ашырыла;

белем бирү практикасында «Сферум» мәгълүмат-коммуникация платформасы, «Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 июлендәге 1341-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2021 – 2027 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планы («юл картасы») гамәлгә ашырыла;

Цифрлы регламентлар конструкторын (КЦР ФРГУ 2.0) кертү юлы белән дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең гади административ регламентларын машина укый торган цифрлы хезмәтләргә этаплап алмаштыру бара.

**Милли мәгариф системасында:**

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау», «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программалары гамәлгә ашырыла;

туган (татар) телен һәм татар әдәбиятын өйрәнү буенча 86 укыту-методик комплекты дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертелде;

Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты белән берлектә дәреслекләр эшләү, аларны сынау һәм кертү, туган тел һәм әдәбият укытучыларына методик ярдәм күрсәтү дәвам итте;

республика муниципаль берәмлекләрендә гражданнарның туган телендә белем алуга, туган телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнүгә хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруны мониторинглау дәвам итә;

туган тел һәм әдәбият укытучылары, милли белем буенча методистлар өчен методик семинарлар оештырыла;

федераль эш программаларын гамәлгә кертү шартларында укытучылар өчен туган телне һәм әдәбиятны укыту буенча методик тәкъдимнәр эшләнде;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән берлектә татар теле һәм

әдәбияты дәресләре өчен видеоматериаллар эшләнде һәм «Татарстан Республикасы электрон мәгарифе» яңартылган платформасында урнаштырылды;

Казан федераль университеты һәм күрше милли республикаларның Мәгарифне үстерү институтлары белән берлектә, укучыларны төп дәүләт имтиханнарына әзерләү өчен, туган (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) теле буенча контроль-үлчәү материаллары банкы төзелде;

Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятен, тарихын һәм традицияләрен өйрәтү максатында якшәмбе мәктәпләре бүлекләре (түгәрәкләре) эшчәнлеген җәелдерү буенча эш дәвам итте, якшәмбе мәктәпләре җитәкчеләре өчен семинарлар үткәрелде;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә этномәдәни юнәлештәге гомуми белем бирү оешмаларына чуваш, удмурт, мари, мордва телләреннән дәреслекләр, интерактив җиһазлар, плакатлар кайтартылды;

туган якны өйрәнү музейлары белән мәгариф оешмалары хезмәттәшлеге оештырылды, килешүләр төзелде;

Татарстан Республикасында һәм республикадан читтә милли мәгариф системасын үстерүгә этәргеч булган инновацион проектларны гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде;

Каюм Насыйри институты үзәкләре эшчәнлегенә оештыру-методик ярдәм күрсәтелә, җәйге профильле тел өйрәнү лагерьләре эше оештырыла;

«Ана теле» онлайн-мәктәбенең эшчәнлеген үзебезнең ил платформасында яңарту буенча эш оештырылды;

билингваль һәм полилингваль тирәлектә эшләү өчен педагогик кадрлар әзерләү эше дәвам итте;

интеллектуаль һәм иҗади бәйгеләр, фәнни-гамәли конференцияләр, туган телләр һәм Татарстан тарихы буенча олимпиадалар үткәрелде, аларда барлыгы 50 меңнән артык кеше катнашты;

Туган (татар) теле укытучыларының бөтенроссия ассоциациясе эше оештырылды, аның эшчәнлегенә методик һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтелде, Россиянең 26 төбәгеннән 800 кеше катнашында Туган тел форумы уздырылды.

**Тәрбия һәм өстәмә белем бирү системасында:**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 2 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары һәм

Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләр исемлегенә керә торган «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм талантларын үстерү системасының нәтиҗәлелеген бәяләү турында» күрсәткеченең «Өстәмә белем алуга җәлеп ителгән 5 яшьтән 18 яшькә (17 яшьне кертеп) кадәрге балалар өлеше (процентларда)» компонентының планлы күрсәткечләренә ирешү буенча эш оештырылды. 2024 елның июленә компонентның күрсәткече 66,88% тәшкил итә;

2023/24 уку елында илнең барлык гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында «Мөһим мәсьәләләр турында сөйләшүләр» дәрестән тыш сәгатьләрен гамәлгә ашыру дәвам итте, алар укучыларның ватанына, анда яшәүче кешеләргә, уникаль тарихка, табигатькә һәм мәдәнияткә ихтирамлы мөнәсәбәтен тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Дәресләрне уздырганда педагоглар Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Мөһим мәсьәләләр турында сөйләшүләр» дәрестән тыш сәгатьләр циклын гамәлгә ашыру буенча бердәм методик тәкъдимнәрне кулланырга, шулай ук төбәк компонентын кертергә мөмкин. Дәресләрнең эчтәлеге укучыларның биш яшь төркеме өчен эшләнә: 1-2 сыйныфлар, 3-4 сыйныфлар, 5-7 сыйныфлар, 8-9 сыйныфлар һәм 10-11 сыйныф укучылары (урта һөнәри белем оешмалары студентлары). 2024 елның 16-17 маенда «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында «Мөһим мәсьәләләр турында сөйләшүләр» проекты кысаларында Россия Федерациясе Президенты Администрациясе вәкиле катнашында форсайт-сессия оештырылды, анда укучылар, студентлар һәм педагоглар сыйныф сәгатьләренең йомгаклау циклына нәтиҗә ясадылар һәм киләсе уку елына темалар тәкъдим иттеләр. Сессиянең алып баручылары, модераторлары һәм оештыручылары буларак, директорның тәрбия буенча киңәшчеләре, муниципаль координаторлар һәм ресурс үзәге белгечләре чыгыш ясады. Форсайт-сессиядә 150 дән артык кеше катнашты;

барлык дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символлары комплектлары белән җиһазландырыла;

978 дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балалар инициативалары үзәкләре җиһазландырылды;

Татарстан Республикасының 978 гомуми белем бирү һәм 88 һөнәри белем бирү оешмасында тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе вазыйфасы кертелде. Әлеге вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр белем бирү оешмасында тәрбия эшчәнлеген үстерүне стратегик планлаштыруда катнаша, балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итә, укучыларны иҗтимагый әһәмиятле проектларга һәм укудан тыш башка эшчәнлеккә җәлеп итә. Тәрбия эшенең календарь планы кысаларында 2023 елның 1 сентябреннән Татарстан

Республикасы территориясендә киңәшчеләр тарафыннан 38 014 чара үткәрелде, аларда 555 230 кеше (шул исәптән 85 842 ата-ана һәм 22 326 педагог) катнашты;

Татарстан Республикасында 8 284 башлангыч сыйныф «Россия бөркетләре» башлангыч сыйныф укучыларының социаль активлыгын үстерү программасын гамәлгә ашыруда катнаша. Программа бөтен илгә танылган «Орленок» балалар сәламәтләндерү үзәге тарафыннан эшләнде, ул дәрес конспектларын, уеннарны һәм дидактик материалларны үз эченә алган әзер укыту-методик комплекттан гыйбарәт. Программа 7 юнәлешкә бүленгән, ул тәрбия эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә бала күнекмәләренең ел саен үсә баруын тәэмин итә;

Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге базасында балаларга өстәмә белем бирү системасында педагогик һәм җитәкче кадрларны үстерү һәм аларның һөнәри осталыгын камилләштерүнең заманча системасы булдырылды. 2023/24 уку елында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды: өстәмә белем бирү оешмаларының төрле категорияле педагоглары һәм җитәкчеләре өчен өчен квалификация күтәрү буенча өстәмә һөнәри программа гамәлгә куелды, барлыгы 491 кеше катнашты; 154 кеше катнашында 7 белем бирү стажировкасы узды; 31 чарада (практик семинарлар, вебинарлар, конференцияләр, фестивальләр, мастер-класслар, түгәрәк өстәлләр) барлыгы 1156 кеше катнашты; тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе хезмәткәрләре өчен 22 һөнәри осталык республика бәйгесе үткәрелде, катнашучыларның гомуми саны – 1901 кеше. Алар арасында иң әһәмиятлеләре – «Арктур» балаларга өстәмә белем бирү хезмәткәрләренең һөнәри осталыгы республика конкурсы, «Йөрәгемне балаларга бирәм» өстәмә белем бирү педагогларының һөнәри осталыгы республика бәйгесе, «Тренер-мастер» өстәмә белем бирү педагогларының һөнәри осталыгы республика конкурсы, балаларга өстәмә белем бирүнең өстенлекле юнәлешләре буенча өстәмә гомуми белем бирү программаларының республика бәйгесе;

Татарстан Республикасында «Кванториум» мәктәп технопарклары челтәрен үстерү дәвам итә. 2021 – 2023 елларда Казан шәһәре Вахитов районының 98 нче (татар-рус) урта гомуми белем бирү мәктәбе, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 нче лицее, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее базаларында «Кванториум» мәктәп технопарклары ачылды, 2024 елда Казан шәһәре Совет районының 174 нче гимназиясе һәм Казан шәһәре Мәскәү районының 64 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе базасында кванториумнар ачу планлаштырыла;

театраль педагогиканы үстерү юнәлешендәге «Мәктәп театры» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2024 елның гыйнварында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар

сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе базасында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Республика мәктәптән тыш эш үзәге белән берлектә «Созвездие-Йолдызлык» хәрәкәте катнашында мәктәп театрлары җитәкчеләре өчен 120 сәгать күләмендә укыту эше гамәлгә ашырылды. 26 педагог белем алды. 2023/24 уку елы дәвамында 1402 гомуми белем бирү оешмасында 1 372 мәктәп театры төзелде һәм эшләде. Берләшмәләрдәге укучыларның гомуми саны – 23 694, шул исәптән 569 ы – сәламәтлеге чикләнгән бала. Хәзерге вакытта 1 242 мәктәп театры республиканың гомуми белем бирү оешмалары базасында эшләп килә. «Мәктәп театры» проектын төзү һәм гамәлгә ашыру планын үтәү күрсәткече 88,2% ны тәшкил итә;

ел саен «Без бергә» халык иҗаты республика балалар фестивале үткәрелә. 2024 елда фестивальдә катнашучыларның гомуми саны Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегеннән якынча 35 000 кеше тәшкил итте;

Татарстан Республикасы укучыларының 77 % ы балалар хәрәкәтенең төрле формаларына җәлеп ителгән, яртысы «Татарстан варислары берлеге» республика иҗтимагый оешмасына керә. «ЮНАРМИЯ» Бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәте Баш штабының 2021 елның 4 августындагы 53 нче номерлы «ЮНАРМИЯ йорты» статусы турында» регламентны раслау турында» боерыгы һәм «ЮНАРМИЯ йорты» статусы турында» Регламентның 4.2.5 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлекләрдә «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтендә 43 ЮНАРМИЯ йорты, 49 муниципаль штаб, 1 211 яшь армияче отряды төзелде, хәрәкәткә 48 994 яшь армияче җәлеп ителде;

муниципаль районнарда мәгариф оешмалары, яшьләр сәясәте оешмалары, мәдәният һәм спорт оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте ячейкалары ачыла, аларга һәрьяклап ресурс һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтелә. Барлык районнарда да җирле бүлекчәләр ачылды, аларның гомуми саны – 45. 2024 елның 15 июленә кадәр хәрәкәткә 57 меңнән артык бала җәлеп ителгән;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 103 144 бала өчен җәйге ял оештырылган: Татарстан Республикасының сәламәтләндерү лагерьларында – 9 383 бала, Кара диңгез яр буе лагерьларында – 675 бала, көндезге лагерьларда – 81 771 бала һәм хезмәт һәм ял лагерьларында – 11 315 яшүсмер;

Мәгариф оешмалары һәм ата-аналар комитетлары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең иң яхшы тәҗрибәләрен ачыклау һәм популярлаштыру максатында, укучыларны тәрбияләүдә ел саен ата-аналар комитетлалары арасында «Тату сыйныф серләре» республика бәйгесе уздырыла. 2023/24 уку елында бәйгедә 3 500 ата-аналар комитеты катнашты, Татарстан

Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим лицее абсолют җиңүче булып танылды;

балаларны тәрбияләү мәсьәләләре буенча квартал саен ата-аналар җәмәгатьчелеге белән эше алып барыла. Ел дәвамында 130 меңнән артык ата-ана катнашында 4 онлайн-утырыш оештырылды;

Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән берлектә сыйныф җитәкчеләре өчен «К-Р сәгате» һәм «Ачык сыйныф» дистанцион мәгълүмати-гамәли лекторийлары оештырыла. 2023/24 уку елында карауларның гомуми саны 87 меңнән артык тәшкил итте;

328 меңнән артык укучы массакүләм спорт-савыктыру чараларында катнаша, 2023 елда 56 меңгә якын укучы норматив тапшыра башлады һәм «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексының мактау билгеләренә ия булды;

1 289 педагог-психолог, 4 психологик-педагогик һәм медицина-социаль үзәге, 27 психологик-педагогик хезмәте тарафыннан психологик-педагогик эш оештырылды;

2023 елның 20-24 ноябрендә һәм 2024 елның 22-26 апрелендә 444 799 укучы, 39 184 педагог һәм 111 813 ата-ана катнашында «Психологик иминлеккә адым» психология атналыгы үткәрелде;

ел саен социаль-психологик тест үткәрелә (алга таба – СПТ). 2023/24 уку елы нәтиҗәләре буенча гомуми белем бирү, урта һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларыннан 206 726 кеше катнашты (тест үтәргә тиешле балалар санының 97 % ы). СПТ нәтиҗәләре буенча гомуми белем бирү оешмаларыннан 9 824 укучы, урта һөнәри белем бирү оешмаларыннан 2 942 студент һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларыннан 634 студент аерым игътибар таләп итүче төркемгә кертелде;

2022 елдан республиканың белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан эшләнгән Гомуми һәм һөнәри белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның аерым категорияләрен исәпкә алу турында нигезләмә уңышлы гамәлгә ашырыла. Нигезләмәне нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен, белем бирү оешмалары директорларының тәрбия эше буенча урынбасарларын, педагог-психологларны һәм социаль педагогларны «риск төркеме» балалары буенча белешмәләр базасын төзү, укучылар арасында анкеталар һәм тест үткәрү үзенчәлекләре, педагогик буталчыклык сәбәпләрен билгеләү, гаиләдә, сыйныфта (төркемдә) һәм белем бирү оешмасында укучыларның хәлен өйрәнү, шулай ук балаларга индивидуаль маршрут карталарын алып бару буенча укыту эше оештырылды. Педагог-психологлар өчен «Куркынычсызлык формуласы» Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча республика белем бирү форумнары оештырылды;

яшүсмерләр арасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә аеруча актуаль мәгълүмат белән педагогларны һәм ата-аналарны вакытында таныштырып бару системасы булдырылды, ул методик тәкъдимнәр эшләү һәм аларны сыйныф җитәкчеләре, мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренең тәрбия эшләре буенча урынбасарлары, педагог-психологлар һәм ата-аналар комитетлары вәкилләре арасында тарату юлы белән башкарылды.

2024 елның 2 маеннан 31 маена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары һәм һөнәри белем бирү оешмалары арасында белем алу мохите куркынычсызлыгына еллык мониторинг оештырылды. Югары белем бирү оешмаларында 33 433 студент (96%) һәм урта махсус белем бирү оешмаларында 41 506 студент (99%) тестта катнашты. Һәр студентка мониторинг нәтиҗәләре буенча социализациянең индивидуаль маршруты эшләнә, ул өстәмә куркынычлар (шәхси, социаль), шулай ук гомуми юнәлештәге чараларны (мәгариф оешмаларында тәрбия эше планы кысаларында) һәм ачыкланган куркынычлар нигезендә индивидуаль профилактик чараларны кертергә мөмкинлек бирә.

**Милли проектларны һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында:**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы 2024 елда «Мәгариф», «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектларын, Россия Федерациясенең 3 дәүләт программасы – «Мәгарифне үстерү», «Гражданнарны һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү», «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда катнаша, башка субсидияләр һәм субвенцияләр ала.

2024 елда республикага җәлеп ителгән акчаның гомуми күләме «Пилотсыз авиация системалары» милли проектын гамәлгә ашыру исәбенә 301,4 млн сум тәшкил итә (федераль бюджеттан – 244,1 млн сум, республика бюджетыннан – 57,3 млн сум);

«Мәгариф» илкүләм проекты – 3 804,8 млн сум, шуларның 3 085,1 млн сумы – федераль бюджет акчалары һәм 719,7 млн сумы – республика бюджеты акчалары;

һәм югарыда күрсәтелгән федераль программаларның башка чаралары – 13,2 млрд сум, шулардан11,5 млрд сум – федераль бюджет акчалары.

**Урта һөнәри белем бирү системасында:**

база предприятиеләренең кадрларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен югары квалификацияле белгечләр әзерләүнең ресурс үзәкләрен төзү эше

дәвам иттерелде: ресурс үзәкләренең гомуми саны 47 гә җитте, 2024 ел ахырына тагын 2 төзеләчәк;

федераль проектларда катнашу кысаларында һөнәри белем бирү оешмалары инфраструктурасы актив үсеш алды;

2022 елдан башлап «Профессионалитет» яңа федераль проекты гамәлгә ашырыла, һөнәри белем бирү оешмалары базасында 14 кластер булдырылды;

белем алучыларга һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга демонстрация имтиханы рәвешендә аттестация үткәрү практикасы киңәя;

пилотсыз авиация системалары буенча практик әзерлек үзәге төзелде;

Татарстан Республикасында һөнәри осталык буенча Бөтенроссия чемпионаты хәрәкәте уңышлы үсеш ала: республика җыелма командасы 2023 елгы чемпионат циклында югары нәтиҗәләргә иреште, барлык милли этапларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы җыелма командасы 148 медаль яулады;

319 компетенция буенча 2024 елда «Профессионаллар» һөнәри осталык чемпионатының һәм Югары технологияләр чемпионатының төбәк этабы уздырылды, ул 5 700 катнашучыны берләштерде;

50 милли һәм 67 региональ компетенция буенча «Абилимпикс» төбәк чемпионаты үткәрелде, ул 1391 катнашучыны берләштерде;

Татарстан Республикасы җыелма командасы 2023 елда «Абилимпикс» Милли чемпионатында гомумкоманда зачетында 2 урынга лаек булды.

**Югары белем системасында:**

Татарстан Республикасы дәүләт заказы нигезендә полилингваль белем бирү оешмаларында эшләү өчен педагогик кадрлар әзерләү эшчәнлеге дәвам иттерелде. 2023/24 уку елында Казан (Идел буе) федераль университетында һәм Чаллы дәүләт педагогика университетында Татарстан Республикасы бюджеты хисабына 624 студент белем ала;

Татарстан Республикасында урнашкан югары белем бирү оешмаларына укырга кергән талантлы яшьләргә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде. 2023/24 уку елында Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге 835 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасында урнашкан 14 югары белем бирү оешмасының 348 студенты Татарстан Республикасы Рәисе стипендиаты булып тора;

югары белем бирү оешмаларының «Мәгариф» һәм «Фән» илкүләм проектларын гамәлгә ашыруда катнашуы кысаларында белем бирү мохитен булдыру эше дәвам итте.

**Өстәмә һөнәри белем бирү һәм методик эш системасында:**

Укытучылар һәм остазлар елында эшләнә башлаган «Татарстанда мәгариф: 100 ел иҗат һәм үсеш» китабы нәшер ителде;

педагогик хезмәткәрләргә һәм җитәкче кадрларга фәнни-методик ярдәмнең бердәм системасына үзгәрешләр, өстәмәләр кертелде;

мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүнең персонификацияләнгән моделе уңышлы эшли;

квалификация күтәрү буенча адреслы программалар эшләү дәвам итә;

укучыларның функциональ белемен формалаштыру һәм үстерү буенча кыска сроклы программалар уңышлы гамәлгә ашырыла;

республиканың 220 мәктәбендә психологик-педагогик юнәлештәге 320 сыйныф ачылды;

республиканың методистлар командалары өчен бердәм методик хезмәтне үстерергә мөмкинлек бирә торган стажировкалар үткәрелде;

төбәктәге методик эшнең нәтиҗәлелеген һәм оперативлыгын тәэмин итү максатыннан республика методик советы эшли;

педагогик кадрларны, шул исәптән полилингваль белем бирү даирәсендә эшләү өчен, максатчан әзерләү кысаларында стипендиаль ярдәм технологияләрен кертү дәвам итә;

җитәкче кадрлар резервын формалаштыру дәвам итә;

белем бирү оешамалары җитәкчеләре өчен уңышлы практикалар белән танышырга һәм алдынгы тәҗрибә алмашырга мөмкинлек бирүче стажировкалар уздыру дәвам итә.

**Тармакны кадрлар белән тәэмин итү системасында:**

Хәзерге вакытта республиканың мәгариф системасында 76 меңнән артык педагогик хезмәткәр эшли, шуларның 32 меңнән артыгы – укытучы һәм 16 меңнән артыгы – тәрбияче. Стажы өч елга кадәр булган укытучылар 8,7 % тәшкил итә (2022/23 уку елында – 8,1 %), тәрбиячеләр – 8,4 % (2022/23 уку елында – 7,2 %). Мәктәпләрнең педагогик кадрлар белән тәэмин ителеше уку елы ахырына 99,6% тәшкил итте.

Региональ белем бирү системасын илнең милли максатларына һәм үсеш бурычларына, җәмгыять үсешенең хәзерге таләпләренә туры килә торган педагогик кадрлар белән тәэмин итү максатында, 2023/24 уку елында түбәндәге эшләр башкарылды:

7 еллык перспективага һәм кыска сроклы перспективага кадрлар ихтыяҗы прогнозы эшләнде; җитәкче кадрлар резервы формалаштырылды;

югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре белән тыгыз хезмәттәшлек оештырылды, ул максатчан әзерлек нигезендә абитуриентлар кабул итүне оештыруны, югары уку йортлары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре чыгарылыш студентларын һәм учреждениеләрен эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтүне исәпкә алып башкарылды; педагогик юнәлешләрне тәмамлаучыларның саны һәм аларның белем бирү оешмаларына эшкә урнашуы күрсәткечләре мониторингы үткәрелде;

педагогларга күрше район мәктәпләрендә дә эшләүгә ярдәм итә торган «Мобиль укытучы» проекты гамәлгә ашырыла;

дүрт ел дәвамында «Земский учитель» федераль программасы актив гамәлгә ашырыла;

республиканың һәр муниципалитетында психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфлар ачылды;

педагогик аттестация системасын модернизацияләү уздырыла: 2023 елның 1 сентябреннән аттестациянең Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләренә аттестация үткәрү тәртибен раслау турында» 2023 елның 24 мартындагы 196 нчы номерлы боерыгы белән расланган яңа тәртибе кертелде; анда ике яңа категория кертелгән: «педагог-методист» һәм «педагог-остаз»; соңгы 5 елда тармак хезмәткәрләренең квалификация категориясе булу буенча уртача республика күрсәткечләре 67% тан 73,19% ка кадәр артты. Югары категориягә – 14 176 кеше, 27,28% (2022/23 уку елында – 15 140 кеше, 22,9%); беренче категориягә – 23 858 кеше, 45,91% (2022/23 уку елында – 31 748 кеше, 48,02%) ия.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм җитәкчеләре вазыйфасына кандидатларны аттестацияләү яңа форматка күчерелде.

**«2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указында билгеләнгән бурычларны гамәлгә ашыру контекстында региональ мәгариф системасын алга таба үстерү һәм эзлекле, инновацион характерын тәэмин итү мәсьәләләрен тикшергәннән соң, киңәшмәдә катнашучылар 2024/25 уку елына түбәндәгеләрне тәкъдим итә:**

**1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:**

**Мәктәпкәчә белем бирү системасында:**

мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә;

мәктәпкәчә белем бирүдән һәркем файдалана алырлык төбәк мәгълүмат системасы – «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – «Электрон балалар бакчасы» АИС) эшчәнлеген даими мониторинглауны тәэмин итәргә;

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары базасында инклюзив төркемнәрнең, консультация үзәкләренең эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату эшен дәвам итәргә;

милли балалар бакчалары челтәрен саклау һәм үстерү максатларында туган телләрендә мәктәпкәчә белем бирүне оештыруның актуаль мәсьәләләре буенча муниципаль идарә органнары методистлары һәм белгечләре белән даими рәвештә киңәшмәләр, семинарлар үткәрергә.

**Гомуми белем бирү системасында (башлангыч, төп, урта гомуми белем):**

гомуми белем бирү оешмаларында «Яшьләр һәм балалар» милли проекты кысаларында математика, физика, химия һәм биология укытуның сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

укучыларның һөнәри билгеләнешен тәэмин итүнең бердәм оештыру моделен алга таба камилләштерү, Белем алучыларны профориентацияләүнең бердәм моделе кысаларында 6-11 сыйныф укучылары арасында чараларны гамәлгә ашыру максатында Татарстан Республикасында «Уңыш» профиль алды әзерлеге һәм профильле укыту системасын үстерү концепциясен 2030 елга кадәр гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

белем бирү сыйфатын бәяләү системасының региональ һәм муниципаль моделен, шул исәптән PISA моделе буенча региональ бәяләү, белем бирү сыйфатын милли тикшерүләрдә (НИКО), бөтенроссия тикшерү эшләрендә (ВПР), шулай ук региональ бәяләү процедуралары технологияләрен исәпкә алып, объективлыкны тәэмин итүгә басым ясап камилләштерү;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы дәүләт йомгаклау аттестациясендә һәм бәяләү чараларында түбән нәтиҗәләр күрсәткән муниципаль берәмлекләрдә укыту-методика эшчәнлеген өйрәнү буенча Координация советы эшен 2024/25 уку елында дәвам итәргә;

түбән нәтиҗәле мәктәпләр һәм белем бирү нәтиҗәләре киму куркынычы шартларында эшләүче мәктәпләр белән эшләү механизмнарын камилләштерүне дәвам итәргә;

сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен 53 дәүләт белем бирү оешмасы һәм республиканың 249 муниципаль гомуми белем бирү оешмасы базасында инклюзив һәм методик ресурс үзәкләренең эш юнәлешләрен камилләштерү эшен дәвам итәргә, фәнни-методик ярдәм күрсәтү буенча база

мәйданчыгы сыйфатында Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институтын билгеләргә;

махсуслаштырылган мәктәпләр челтәре – сәләтле балалар өчен 15 махсуслаштырылган интернат тибындагы оешма, 15 кадет мәктәбе һәм интернат мәктәп, «Инженерлык республикасы» проектының 10 мәктәбе, 33 «РОСНАНО» мәктәбе эшчәнлегенә методик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашырырга;

мәгарифнең муниципаль идарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә «Һәр баланың уңышы» проектында катнашучылар саны турындагы максатчан күрсәткечне үтәү өлешендә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә: «Киләчәккә билет» проекты; «ПроеКТОрия» ачык дәресләр циклы тәҗрибәсен исәпкә алып гамәлгә ашырыла торган ачык онлайн-дәресләр, «Россия – минем офыклар» яисә «Казан ачык талантлар университеты» белән берлектә белем бирү оешмасы дәрәҗәсендә иртә профориентация һәм һөнәри үзбилгеләнеш юнәлешләрен дә кертеп, мөмкинлекләре, функцияләре һәм нәтиҗәләре буенча башлангыч юнәлештәге башка проектлар;

Бәйсез Дәүләтләр Берлеге һәм БРИКС дәүләтара берләшмәсе кысаларында бердәм фәнни-технологик киңлек төзүнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында полилингваль белем бирүнең яңартылган концепциясен эшләргә;

Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты һәм Казан шәһәренең «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе составындагы ресурс методик үзәк базасында, рус, татар һәм инглиз телләрендә, шул исәптән этномәдәни мирасны, полилингваль һәм полимәдәни компонентларны куллану нигезендә, конкурентлыкка сәләтле белем бирүне тәэмин итә торган заманча мәктәп моделе буларак, полилингваль комплексларга методик ярдәм оештыру;

Республика олимпиада үзәге базасында сәләтле укучыларны ачыклау, аларга ярдәм итү буенча эшне камилләштерергә, профильле сменалар санын һәм укыту-тренировка җыеннарын уздыруның сыйфатын арттырырга;

Республика олимпиада үзәге базасында сәләтле укучыларны ачыклау һәм аларның эшен камилләштерергә, профильле сменалар санын һәм укыту-күнекмә җыеннары уздыруның сыйфатын арттырырга;

«Сириус» белем бирү үзәге моделе буенча региональ үзәк базасында «Казан талантлар ачык университеты 2.0» белән берлектә сәләтле балалар өчен «Сәнгать», «Фән», «Спорт» юнәлешләре буенча ел дәвамында белем бирү сменалары үткәрүне тәэмин итәргә;

математик һәм табигый-фәнни белем бирүне, профильле белем бирүне үстерү өчен шартларны камилләштерү буенча чаралар исемлеген билгеләргә (физика, химия, биология һәм информатика фәннәре кабинетларын җиһазлау, табигый-фәнни һәм инженерлык белемен

популярлаштыру), белем бирү оешмаларын белем бирү шул исәптән «Ватанны саклау һәм яклау нигезләре», «Хезмәт (Технология)» фәннәре буенча, программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле укыту һәм тәрбия чаралары белән җиһазландыру;

элегрәк төзелгән «Үсеш ноктасы», «Кванториум», «IT-куб» мәгариф үзәкләренең үзара хезмәттәшлеге һәм ресурслардан файдалану модельләрен камилләштерергә.

**Мәгарифне цифрлы трансформацияләү өлкәсендә:**

«цифрлы өлгереш» күрсәткечләренә ирешү кысаларында мәгариф өлкәсендә цифрлы трансформация проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә Татарстан Республикасы медиакиңлегендә балаларның мәгълүмати куркынычсызлыгын тәэмин итү эшен дәвам итәргә, мәгариф оешмаларында шәхси белешмәләрнең мәгълүмати куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм яклау чараларын көчәйтергә;

Цифрлы регламентлар конструкторын (КЦР ФРГУ 2.0) кертү юлы белән дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең гадәти административ регламентларын машина укый торган цифрлы хезмәтләргә этаплап алмаштыруны дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә «Татарстан Республикасының электрон мәгарифе» edu.tatar.ru модернизацияләнгән дәүләт мәгълүмат системасын кулланышка кертү һәм система мөмкинлекләрен нәтиҗәле үзләштерүне тәэмин итү чараларын дәвам итәргә;

«Минем мәктәп» федераль дәүләт мәгълүмат системасының актуаль мөмкинлекләре турында белем бирү оешмалары педагогларына, укучыларына һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) даими рәвештә мәгълүмат җиткереп баруны тәэмин итәргә, системада теркәлү һәм белем бирү процессында аның сервисларын, шул исәптән цифрлы белем бирү контенты китапханәсен куллану мәсьәләләре буенча кирәкле мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтергә;

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында «Киләчәк коды» федераль проектында, «Яндекс.Лицей» белем бирү проектында катнашкан укучыларның санын арттыру буенча эшне дәвам итәргә;

өйдә белем алу кысаларында махсус белем алу ихтыяҗлары булган балаларның эш урыннарын махсуслаштырылган компьютер җиһазлары белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;

2025 – 2030 елларга мәгарифне цифрлы трансформацияләү өлкәсендә илкүләм программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру эшен оештырырга.

**Милли мәгариф өлкәсендә:**

белем бирү оешмаларында укыту-тәрбия процессын этномәдәни мирасны, полилингваль һәм полимәдәни компонентларны нәтиҗәле файдалану нигезендә оештыру юнәлешендә эшчәнлекне дәвам итәргә;

интеграция һәм дәвамчанлык принципларына нигезләнеп, мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларында туган телне өзлексез укытуны тәэмин итү буенча методик эшне көчәйтергә;

муниципалитетларның милли һәм территориаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, туган телдә гомуми белем бирү оешмаларына методик ярдәмне күрсәтүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты белән берлектә дәреслекләр эшләүне, аларны апробацияләү һәм гамәлгә кертү, туган тел һәм әдәбият укытучыларына методик ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә;

«Татарстан Республикасының электрон мәгарифе» платформасын Татарстан халыкларының туган телләрендә эшләнгән контент белән тулыландыру эшен дәвам итәргә;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тәкъдимнәрен һәм Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча элегрәк төзелгән региональ укыту әсбапларын исәпкә алып, «Туган як тарихы» дәреслеген әзерләү эшен башкарырга;

мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларында тел мохитен үстерү, шулай ук өстәмә белем бирү кысаларында республикада яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәтү эшен дәвам итәргә;

Идел буе халыкларының туган телләрендә олимпиадалар һәм башка интеллектуаль һәм иҗади бәйгеләр уздыру юлы белән сәләтле балаларны ачыкларга һәм аларның үсешен тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә һәм Россия Федерациясенең татарлар күпләп яши торган төбәкләрендә Бөтенроссия (туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе бүлекчәләренең эшен оештырырга, аларның эшчәнлегенә методик һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтергә.

**Тәрбия һәм өстәмә белем бирү системасында:**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыева җитәкчелегендәге, Мәгариф һәм фән, мәдәният, спорт, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, экология министрлыклары вәкилләреннән үз эченә алган ведомствоара эш төркеме эшчәнлеге кысаларында түбәндәгеләрне үтәүне тәэмин итәргә:

2030 елга кадәр балаларга өстәмә белем бирү концепциясе һәм Татарстан Республикасында максатчан күрсәткечләрне гамәлгә ашыру буенча эш планы;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә балаларга өстәмә белем бирү системасында социаль заказ кертү чаралары, шул исәптән балаларга өстәмә белем бирү системасында белем бирү сыйфатын яхшыртуны тәэмин итә торган финанслау системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-финанс механизмнарын булдыру, балаларга өстәмә белем бирү системасында конкурентлык мохите тудыру, шулай ук балаларның өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга тигез мөмкинлеген тәэмин итү;

кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында тәрбия үсеше стратегиясе чаралары планын үтәүне тәэмин итәргә;

**Опека һәм попечительлек системасында:**

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкында исәптә торучы ятим балалар санын киметү буенча ведомствоара эшне дәвам итәргә;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүче өлкән яшьтәге балаларның һәм сәламәтлекләре чикләнгән балаларны гаиләгә урнаштыруның нәтиҗәле формаларын гамәлгә ашырырга;

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру өлкәсендә эшләүче белгечләрнең һөнәри компетентлыгын һәм хезмәт сыйфатын күтәрү аша ятим балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә ярдәмоештырырга, балаларның кабат ятимлек дәрәҗәсен киметүне тәэмин итәргә;

ятим балаларны Татарстан Республикасында торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешлеләр исемлегенә кертүнең нигезлелеге өчен законнар таләпләренең үтәлешен, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар тарафыннан торак урыннардан файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп торуны көчәйтү чаралары планын гамәлгә ашырырга.

**Милли проектларны, дәүләт һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында:**

Россия Федерациясенең «Мәгарифне үстерү», «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше», «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программалары чараларын үтәүне һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итәргә.

**Урта һөнәри белем бирү системасында:**

ресурс үзәкләре челтәрен киңәйтү эшен алып барырга;

«Профессионалитет» федераль проектында катнашучылар, җиңүчеләр санын арттырырга;

урта һөнәри белем бирүне таләп итә торган аеруча кирәкле һөнәрләр буенча программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә (ТОП-50);

демонстрацион имтихан механизмын кулланып аттестацияләү гамәлгә ашырыла торган һөнәри белем бирү оешмалары өлешен арттырырга;

предприятиеләрнең кадрларга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен «Профессионалитет» федераль проекты программалары буенча кадрлар әзерләүне арттырырга;

оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең кадрларга ихтыяҗын тәэмин итү эшен дәвам итәргә;

«Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» белән берлектә Татарстан Республикасында «Профессионаллар» һәм «Абилимпикс» һөнәри осталык буенча чемпионат хәрәкәтләрен үстерү эшен дәвам итәргә;

һөнәри белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең һөнәри компетентлык дәрәҗәсен нәтиҗәле арттырырга;

«Дәүләт хезмәтләрнең бердәм порталы аша урта һөнәри белем бирү программалары буенча укуга гаризаларны кабул итү һәм теркәү» күрсәткечен тулы күләмдә үтәүне тәэмин итәргә;

оешмаларны террорчылыктан саклау юнәлешендә өстәмә чаралар комплексы эшләргә.

**Югары белем бирү системасында:**

Казан (Идел буе) федераль университеты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты белән берлектә педагогик кадрлар әзерләү системасын модернизацияләүгә юнәлтелгән чаралар комплексын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны дәвам итәргә, шулай ук 2024/25 уку елында, билингваль һәм полилингваль белем бирү тирәлегендә эшләү өчен, гомуми саны 600 дән ким булмаган студентка максатчан белем бирүне тәэмин итәргә;

«Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасының максатчан күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә, республикада талантлы яшьләрне беркетү өчен шартлар тудыру, Россия Федерациясенең башка субъектларыннан абитуриентлар җәлеп итү эшен дәвам итәргә.

**Өстәмә һөнәри белем бирү һәм методик эш системасында:**

«Физмат прорыв» республика проектын тормышка ашыра башларга (укытучыларга методик ярдәм, педагогларга һәм мәктәпләргә грант ярдәме күрсәтү);

Укытучылар өчен «Хезмәт (технология)» һәм «Ватанны саклау һәм куркынычсызлык нигезләре» яңа уку предметларын укытуда методик ярдәм оештырырга;

– «Воин» һәм «Патриот» үзәкләре, БАС (пилотсыз авиация системасы) өлкәсендәге техникумнар базасында «Ватанны саклау һәм куркынычсызлык нигезләре» укытучыларын практик яктан әзерләүне оештырырга;

кадрлар потенциалын камилләштерү, индивидуаль үсеш траекторияләрен төзү, шул исәптән өстәмә һөнәри белем бирүнең яңа формаларын һәм модельләрен эшләү максатында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри кыенлыкларын ачыклау системасын эшләүне дәвам итәргә;

педагогик хезмәткәрләр һәм идарәче кадрларга фәнни-методик ярдәм бердәм системасын формалаштыру һәм үстерү мөмкинлеген бирә торган өзлексез педагогик белем бирүне үстерү эшен дәвам итәргә;

барлык бәяләү процедураларын исәпкә алып, өстәмә һөнәри белем бирү программаларының адреслылыгын арттыру юлы белән педагогларның предметлы, методик, психологик-педагогик, коммуникатив компетенцияләрен камилләштерү эшен дәвам итәргә;

яңартылган ФДББСны гамәлгә ашыруга, ФТББПны кертүгә һәм укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерүгә бәйле мәсьәләләрдә педагогларга методик ярдәмне көчәйтергә;

«Татарстан Республикасы электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасында диагностика нәтиҗәләрен исәпкә алып, бәяләү инструментарийларын камилләштерергә;

укытучы үсешенә ярдәмнең һөнәри компетенцияләр кытлыгын билгеләүне, стажировкаларның тармакланган системасын, алдынгы цифрлы технологияләр белән укытуны, тәҗрибәне киң алмашу һәм ирекле иҗади үсеш мөмкинлекләрен үз эченә алган, мотивлаштыра торган методикаларын формалаштыру;

белем бирү процессында катнашучыларга психологик ярдәм мәсьәләләре буенча педагоглар һәм сыйныф җитәкчеләре өчен кыска сроклы укыту программаларын тормышка ашырырга;

республикада муниципаль методик хезмәтнең бердәм системасын үстерүне дәвам итәргә;

педагогик белем бирү юнәлешләре буенча югары уку йортларына максатчан кабул итү механизмнарын камилләштерү һәм яшь укытучыларны мөгаллим һөнәренә беркетүгә ярдәм итә торган шартлар тудыру эшен, шул исәптән «Россиядә эш» бердәм цифрлы платформасын кулланып, дәвам итәргә;

булачак абитуриентларның һөнәр белән таныштыру эшен тормышка ашыру, үз юлларын табу һәм педагог һөнәренә тартылу өчен киңлек буларак, психологик-педагогик юнәлештәге профильле сыйныфлар челтәрен киңәйтергә;

җитәкче кадрлар резервын формалаштыру системасын камилләштерү эшен активлаштырырга;

белем бирү оешмалары җитәкчеләрен һәм идарә итү командаларын һөнәри үстерү эшен стажировкалар, мастер-класслар, авторлык программалары рәвешендә дәвам итәргә.

**Фәнни-технологик сәясәт системасында:**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасында катнашучы югары белем бирү оешмаларына үсеш программаларын гамәлгә ашыруда мәгълүмати-методик һәм оештыру-техник ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

**2. Татарстан Республикасы мәгариф белән идарә итүнең муниципаль органнарына:**

**Мәктәпкәчә белем бирү системасында:**

мәктәпкәчә белемгә мохтаҗ барлык балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән максималь тәэмин итү чараларын күрергә;

«Электрон балалар бакчасы» автоматлашкан мәгълүмат системасына кертелә торган күрсәткечләрнең тулылыгын һәм актуальлеген тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

милли мәгарифне үстерү буенча муниципаль «юл карталары» чараларын үтәүне, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының тел статусы нигезендә белем бирү процессын оештыруның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәргә;

балалар бакчаларында, шул исәптән сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен дә, мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартына туры килә торган федераль белем бирү программаларын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә,

территориясендә консультация үзәкләре булдырылган һәм «Балалар бакчасы – үсеш маршрутлары» федераль гранты гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекләр җитәкчеләренә акчаларны 2024 елның 31 декабренә кадәр тулысынча үзләштерүне тәэмин итәргә.

**Гомуми белем бирү системасында:**

«Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» региональ проектын гамәлгә ашыруга һәм «Россия Мәгариф министрлыгы мәктәбе» проектында катнашучы мәктәпләргә комплексly ярдәмне тәэмин итәргә;

гомуми белем бирү оешмалары – «Үсеш ноктасы» цифрлы һәм гуманитар профильле үзәкләр, табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре инфраструктурасын гомуммәдәни компетенцияләрне, функциональ, табигый һәм цифрлы грамоталылыкны үстерү җәмәгать пространствосы буларак, укучылар тарафыннан төп һәм өстәмә белем бирү программаларын үзләштерү барышында укучыларның проект эшчәнлеген оештыруны тәэмин итәргә;

муниципаль берәмлек территориясендә төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында профильгә әзерлек һәм профильле укыту системасын үстерү буенча чараларны билгеләргә, төп башкаруда катнашучылар буларак, һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын (булган очракта), территориаль хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрен, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм эшчәнлек алып баручы сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен җәлеп итәргә;

гомумбелем бирү оешмалары кабул иткән белем бирү һәм аерым предметларны тирәнтен өйрәнү программаларын, территорияне икътисади үстерү үзенчәлекләрен, кадрларга булган ихтыяҗны, гамәлдәге һөнәри белем бирү оешмаларын исәпкә алып, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан мәктәпләрнең гомуми санынннан 25% тан ким булмаган сандагы, профориентиацион минимумны үтәүдә «алдынгы дәрәҗәле» мәктәпләр исемлеген билгеләп, профориентация минимумын гамәлгә ашыру буенча чараларның муниципаль планнарын эшләргә һәм расларга;

сәләтле балаларны ачыклау һәм үстерү, сәләтле яшьләрне кызыксындыру һәм бүләкләү системасын киңәйтүгә ярдәм итәргә;

чыгарылыш сыйныф укучылары тарафыннан алга таба белем алу траекториясен аңлы рәвештә сайлау өчен шартлар булдырырга; имтихан предметларын, профильне, гамәлгә ашырыла торган программаларның юнәлешен исәпкә алып, сайлау барышында 9-11 сыйныфларда укучыларны мотивацияләү эшен көчәйтергә;

яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчүдә методик ярдәм буларак федераль төп һәм адаптацияләнгән гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын билгеләргә;

балалар һәм яшьләр өчен конкурс чараларын, каникуллар вакыты өчен һөнәри юнәлешле мәктәпләр, профильле һәм махсус сменалар үткәрүне тәэмин итәргә (чаралар үткәрү графигы нигезендә);

«Минем беренче һөнәрем» проектын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырырга, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары һәм урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмалары, һөнәри белем программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар арасында программаны гамәлгә ашыруның челтәр формасы турында шартнамәләр төзү юлы белән;

белем бирүнең сыйфатын бәяләүнең объектив системасын формалаштыру чараларын гамәлгә ашыру юнәлешендә гомуми белем бирү оешмаларын оештыру-методик ярдәм белән тәэмин итәргә; Россия Мәгариф министрлыгы һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тәкъдимнәре нигезендә тикшерү һәм диагностика эшләре графигын оптимальләштерүне тәэмин итәргә; белем бирү нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләргә һәм белем бирү нәтиҗәләре киму куркынычы шартларында эшләүче мәктәпләргә адреслы методик ярдәм күрсәтүне, уку-укыту уңышсызлыгын профилактикалауны тәэмин итәргә;

үзлегеннән белем алу һәм укытуның гаилә формасында белем алган укучыларга даими контроль ясарга.

**Районның муниципаль методик эше системасында:**

«Физик-математик алгарыш» республика проектын гамәлгә ашыра башларга (укытучыларны, мәктәпләрне оештыру-методик яктан тәэмин итү);

«Хезмәт (технология)» һәм «Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре» яңа уку предметлары укытучыларына методик ярдәм оештырырга;

«Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре» укытучыларын – «Воин» һәм «Патриот» үзәкләре, пилотсыз авиация системасы өлкәсендәге педагогларны техникумнар базасында практик яктан әзерләүне оештырырга;

яңартылган ФДББСны гамәлгә ашыруга, ФТББПны кертүгә һәм укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерүгә бәйле мәсьәләләрдә педагогларга методик ярдәмне көчәйтергә;

районда методик эш системасын үстерүне дәвам итәргә;

иң яхшы укучыларны укытучы һөнәренә җәлеп итүгә юнәлдерелгән актив һөнәри юнәлеш бирү эшен дәвам итәргә;

психологик-педагогик сыйныфлар кысаларында табигый-фәнни профиль булдыру мөмкинлекләрен карарга;

югары уку йортларына укырга максатчан кабул итү, шул исәптән стипендиаль ярдәм күрсәтү һәм полилингваль әзерлек республика проекты буенча эшне активлаштырырга;

яшь укытучыларны район мәктәпләрендә беркетү эшен көчәйтергә, муниципаль дәрәҗәдә мотивация һәм социаль ярдәм чаралары эшләргә.

**Милли мәгариф системасында:**

мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларында туган тел мохите булдыру һәм үстерү, шулай ук өстәмә белем бирү кысаларында муниципаль

берәмлек территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү эшен оештырырга;

төп дәүләт имтиханы кысаларында ата-аналар белән туган телдә белем бирү, туган телләрне өйрәнү мөмкинлекләре турында аңлату эшләре алып барырга;

укучыларның һәм педагогларның республика конференцияләрендә һәм бәйгеләрендә актив катнашуларын тәэмин итәргә;

муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, мәдәниятләрен һәм традицияләрен өйрәнү буенча якшәмбе мәктәпләре бүлекләренең эшен оештырырга, аларның эшчәнлеген популярлаштыру буенча даими эш алып барырга;

массакүләм мәгълүмат чараларында, рәсми аккаунтларда һәм белем бирү оешмалары сайтларында, социаль челтәрләрдә туган телләрдәге чараларны киң яктыртуны тәэмин итәргә;

белем бирү оешмаларының Россия Федерациясе төбәкләрендә урнашкан этномәдәни компонентлы мәктәпләр белән хезмәттәшлеген активлаштырырга, әлеге эшкә Татарстан халыкларының милли-мәдәни автономияләрен җәлеп итәргә.

**Балаларны тәрбияләү һәм аларга өстәмә белем бирү системасында:**

2030 елга кадәр балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча эш планын һәм Татарстан Республикасында өстәмә гомуми белем бирү программаларының эчтәлеген яңартуга юнәлдерелгән максатчан күрсәткечләрне гамәлгә ашыру чараларына актив катнашырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә «Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 2 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләр исемлегенә кергән «Балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм талантларын үстерү системасының нәтиҗәлелеген бәяләү турында» күрсәткеченең «Өстәмә белем алуга җәлеп ителгән 5 яшьтән 18 яшькә (17 яшьне кертеп) кадәрге балалар өлеше (процентларда)» компонентының планлы күрсәткечләрен 2024 елның декабренә кадәр 80 % тан югарырак булуына ирешү эшен оештырырга.

**Опека һәм попечительлек системасында:**

баланы туган гаиләдә тәрбияләү өстенлеген тәэмин итәргә, гаилә, бала, ата-ана җаваплылыгы кыйммәтләрен формалаштырырга;

ата-ана хокуклары чикләнгән һәм ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналар белән эшләү программаларын гамәлгә кертергә, тәрбияләнүчеләрне үз гаиләләренә кире кайтару максатында ата-ана хокукларын торгызу процессын күзәтеп барырга;

ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыруның гаилә формаларын киңәйтүне мәгълүмати тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын булдырырга;

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның ялын, мәшгульлеген һәм аларны эшкә урнаштыруны аерым контрольгә алырга;

балаларга карата көч куллану һәм алар белән рәхимсез эш итү проблемалары буенча мәгълүмати-аңлату мәйданчыклары оештырырга;

гаиләләрне социаль реабилитацияләүнең социаль ятимлекне профилактикалауга, балаларны алмаштыручы гаиләләрдән кайтаруга юнәлдерелгән алдынгы практикаларын һәм яңа технологияләрен кулланырга;

ятим балаларга беркетелгән торакның саклану мәсьәләсен аерым контрольгә алырга.

**Милли проектларны, дәүләт һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында:**

федераль программалар һәм проектлар кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны тикшереп торырга;

грант алучы белем бирү оешмаларына федераль программалар һәм проектлар чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән, расланган федераль, республика һәм бюджеттан тыш чараларны тулысынча үзләштерүне тәэмин итәргә;

федераль проектларның максатларга, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектлар кысаларында сатып алынган җиһазларның, укыту һәм тәрбия чараларының белем бирү процессында фактта файдалануына даими мониторинг ясарга.

**Мәгарифне кадрлар белән тәэмин итү системасында:**

муниципаль берәмлектәге (торак пунктлардагы) демографик вәзгыятьне, табигый сәбәпләр аркасында (пенсиягә чыгу һ.б.), мәгариф оешмаларын ачуга (реструктуризацияләүгә) бәйле рәвештә кадрлар составы үзгәрешен исәпкә алып, озак сроклы һәм якын киләчәккә педагогик кадрларга ихтыяҗ турында актуаль фаразлар бирергә;

белем бирү оешмаларына педагогларның ачык вакансияләренә чакыру максатында югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары белән эш алып барырга;

белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең аттестация барышында төп һөнәри компетентцияләрен камилләштерү процессына фәнни-методик ярдәм күрсәтү чаралары комплексын эшләргә;

муниципаль чаралар кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт һәм тармак бүләкләре белән бүләкләнгән иң яхшы педагогик династияләрне, иң яхшы мәгариф хезмәткәрләрен бүләкләү мөмкинлеген карарга.

**3. Татарстан Республикасы территориясендә эшли торган югары белем бирү оешмаларына:**

Татарстан Республикасының мәгариф-җитештерү ресурсларыннан оптималь файдалану өчен уңайлы шартлар тудыруга һәм башкарма хакимият органнары һәм мәгариф өлкәсендә җирле үзидарә органнары дәрәҗәсендә килештерелгән кадрлар һәм мәгариф сәясәте булдыруга юнәлдерелгән Укучыларга һөнәри юнәлеш бирүнең бердәм моделе буенча 6-11 сыйныф укучылары арасында чараларны гамәлгә ашыру кысаларында гомуми белем бирү оешмалары белән махсуслаштырылган һөнәри сыйныфлар челтәрен (авиа-, суднолар төзелеше сыйныфлары, энергосыйныфлар, агросыйныфлар, «Промхимтех»-сыйныфлар, медицина сыйныфлары, кадет сыйныфлары, экология сыйныфлары, геологик мәйданчыклар, IT-класслар һ.б.) үстерү юнәлешендә үзара хезмәттәшлекне дәвам итәргә;

«Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруда актив катнашуны дәвам итәргә.

**4. Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институтына:**

түбәндәге юнәлешләрдә фәнни-методик ярдәм күрсәтергә:

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында «Уңыш» профиль алды әзерлеге һәм профильле укыту системасын үстерү концепциясе чаралары, шул исәптән аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен анализлау һәм анализ нәтиҗәләре буенча адреслы тәкъдимнәр эшләү;

инновацион программалар һәм технологияләр апробацияләү буенча федераль, республика мәйданчыклары эшчәнлеге;

мәктәпкәчә белемнең федераль белем бирү программасы, федераль төп белем бирү программасы, федераль адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча квалификация күтәрү курслары;

яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре һәм кабул ителгән федераль төп гомуми белем бирү программалары таләпләре нигезендә, 2024 елгы чыгарылыш укучыларының дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль методик хезмәтләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә методик ярдәмне дәвам итәргә;

педагогларның һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең, шул исәптән адаптацияләнгән гомуми белем бирү һәм балигъ булмаган укучыларны хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә әзерләү максаты куелган программаларны гамәлгә ашыручыларның да, һөнәри осталыгын үстерү, гомуми белем бирү оешмалары эшенең уңай тәҗрибәсен гомумиләштерү, шул исәптән башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең сыйфатын бәяләү мәсьәләләре буенча эшчәнлекне дәвам итәргә.

**5. Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларына:**

**Милли проектларны, дәүләт һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру кысаларында:**

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән төзелгән килешүләр кысаларында йөкләмәләрне йөз процент үтәүне тәэмин итәргә;

күрсәтелгән таләпләр буенча 2025 елның 15 гыйнварына кадәр еллык хисапларны һәм документларны әзерләргә;

федераль, региональ бюджетлардан һәм оешмаларның бюджеттан тыш фондыннан алынган акчаларны үз вакытында һәм максатчан үзләштерүне тәэмин итәргә;

милли проектлар, дәүләт һәм федераль программалар кысаларында сатып алынган җиһазларның, белем бирү һәм тәрбия чараларының эшчәнлеген һәм даими файдалануын тәэмин итәргә.

**Гомуми белем бирү системасында (башлангыч, төп, урта гомуми белем):**

һәр укучының сәләтен ачыклау, ярдәм итү һәм үстерү буенча системалы эшне дәвам итәргә;

белем бирү эшчәнлеген яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә оештыруны планлы рәвештә дәвам итәргә;

яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары һәм кабул ителгән федераль төп гомуми белем бирү программалары таләпләре нигезендә төп һәм адаптацияләнгән гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

«Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре», «Хезмәт (Технология)» укыту предметлары укытучыларының квалификациясен күтәрү чаралары системасын булдырырга;

укучыларны профориентацияләүнең бердәм моделе кысаларында 6-11 сыйныфлар укучылары арасында чаралар программасын гамәлгә ашыруны, 2024/25 уку елы ахырына күрсәткеч буларак, «төп» яисә «алга киткән» дәрәҗәгә ирешүне тәэмин итәргә;

педагогларның функциональ грамоталылыгын үстерү һәм Россия электрон мәктәбе биремнәре банкын куллану буенча мәктәп методик хезмәтләренең эшен активлаштырырга;

белем бирү оешмасында белем бирүнең сыйфатын бәяләүнең объектив эчке системасын формалаштыру эшен дәвам итәргә; Россия Мәгариф министрлыгы һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тәкъдимнәре нигезендә тикшерү һәм диагностика эшләре графикларын оптимальләштерүне тәэмин итәргә; мәгариф оешмасында түбән белем бирү нәтиҗәләрен профилактикалау чараларын гамәлгә ашырырга.

**Милли мәгариф системасында:**

гражданнарның туган телдә белем алуга һәм туган телләрен өйрәнүгә конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

белем алучыларның этник үзаңын формалаштыруга, үз халкының, үз төбәгенең тарихы, мәдәнияте, Россия һәм дөнья халыкларының мәдәни мирасы нигезләрен үзләштерүгә юнәлдерелгән тәрбия эше оештырырга;

балаларда туган телгә һәм милли кыйммәтләргә, традицияләргә мәхәббәт тәрбияләүдә гаиләнең ролен популярлаштыру эшен активлаштырырга;

сәләтле укучыларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү буенча системалы эш оештырырга.

**Балаларны тәрбияләү һәм аларга өстәмә белем бирү системасында:**

балалар инициативалары үзәген һәм тәрбия эше штабын булдыруны тәэмин итәргә;

«Россия бөркетләре» социаль-педагогик программасында барлык гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары катнашуын тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт флагларын күтәрү, «Мөһим мәсьәләләр турында сөйләшүләр» дәрестән тыш сәгатьләрен үткәрүне атна саен гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

«Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия балалар-яшүсмерләр хәрәкәте муниципаль кураторлары белән берлектә гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларын һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларын хәрәкәткә җәлеп итүне тәэмин итәргә, барлык мәгариф оешмаларында хәрәкәтнең беренчел бүлекләрен ачарга;

мәктәп театрларын һәм мәктәп музейларын ачуны 2024 елның декабренә кадәр барлык мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырырга, шул исәптән мәктәп музейларын паспортлаштырырга;

яңа ачылган гомуми белем бирү оешмалары базасында мәктәп спорт клублары төзү һәм аны «Мәгарифтә физик культура һәм спорт» Бердәм

мәгълүмат мәйданчыгында мәктәп спорт клублары реестрында теркәү эшен оештырырга (https://еип-фкис.рф/);

һәр муниципаль берәмлектә 2024 елның 1 октябренә кадәр ЮНАРМИЯ йортлары төзергә;

республикада наркологик вәзгыятьне минимальләштерү буенча укучылар белән хезмәттәшлек итү механизмнары һәм ысуллары өлешендә профилактик юнәлеш программалары эчтәлеген яңартырга;

балалар һәм яшүсмерләрнең суицидаль тәртибен ачыклау буенча ата-аналар һәм педагоглар өчен семинарлар үткәрергә;

исәпкә алуның төрле төрләрендә торучы балаларны дәрестән тыш вакытта эш белән тәэмин итүне оештырырга.